КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 610

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге үзәк махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр шахмат мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесен оештыру турында» 2009 ел, 31 декабрь, 917 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге үзәк махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр шахмат мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесен оештыру турында» 2009 ел, 31 декабрь, 917 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне керергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында»;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге үзәк махсуслаштырылган олимпия резервы балалар-үсмерләр шахмат мәктәбе» дәүләт автоном өстәмә белем бирү учреждениесен» сүзләрен « Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесен» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган автоном учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.»;

5 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин